СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.05.2025 № 58/2

На №__________от______________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы законнарны үтәү буенча эшнең торышы турында

«Тукай муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы законнарны үтәү буенча эшнең торышы турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.
2. «2015-2027 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында милли сәясәтне гамәлгә ашыру» программасы чараларын үтәү буенча эшне дәвам итәргә.
3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче вазыйфаи затларга, муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу, алар тарафыннан коррупциягә каршы тору максатында билгеләнгән бурычларны үтәү таләпләрен тайпылышсыз үтәүне тәэмин итәргә.
4. Коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча җаваплы вазыйфаи затларга:

- муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар арасында коррупцион күренешләрне кисәтү һәм булдырмау буенча профилактик эшне көчәйтергә;

- законнарда билгеләнгән срокларда барлык муниципаль хезмәткәрләрнең һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, муниципаль учреждение җитәкчеләренең, аларның хатыннарының (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын тикшерү һәм анализ үткәрүне, шулай ук

хезмәттәге чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу, коррупциягә каршы тору максатында билгеләнгән бурычларны үтәү буенча тикшерүләр үткәрүне оештырырга;

- коррупцион һәм башка хокук бозулар предметына гражданнар мөрәҗәгатьләренә, Совет һәм район Башкарма комитеты хезмәткәрләрендә мәнфәгатьләр каршылыгына, хезмәткәрләрнең Этика һәм хезмәт тәртибе кодексын бозуга китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык булуга анализ ясарга.

5. «Тукай муниципаль районы капиталь төзелеш хезмәте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Тукай муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе, район Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге белән берлектә, авыл җирлекләре территорияләрендә урнашкан социаль инфраструктура һәм күп фатирлы йортларның төзекләндерелгән объектларында башкарылган эшләрнең, шулай ук гражданнарның үзара салымы средстволары хисабына башкарылган эшләрнең сыйфатлы башкарылуын контрольдә тотарга.

6. Районның финанс-бюджет палатасына:

- җирле бюджет акчаларын нәтиҗәле файдалануны контрольдә тотуны оештырырга;

- эчке стандартларны һәм процедураларны, шул исәптән бюджетны төзү һәм үтәү, бюджет исәбен алып бару, бюджет хисаплылыгын төзү, административ регламентларны үтәү, шулай ук бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген (нәтиҗәлелеген һәм экономиялелеген) арттыруга юнәлдерелгән чараларны әзерләү һәм гамәлгә ашыруны оештыруга юнәлдерелгән финанс контроленең сыйфатын һәм ышанычлылыгын арттыру буенча чаралар күрергә.

7. Районның мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына мөлкәт белән идарә итү, файдалану һәм эш итү тәртибен җайга салучы гамәлдәге законнарны бозу очракларын ачыклау һәм мондый хокук бозуларга юл куйган затларны билгеләү буенча даими эш алып барырга.

8. Муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаны биләүче затларга тыюлар, чикләүләр, таләпләр рәвешендә белдерелгән, коррупциягә каршы тотрыклы тәртип формалаштыруны күздә тоткан коррупциягә каршы законнарны төгәл үтәргә.

9. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә, Тукай муниципаль районы пресса хезмәтенә район халкына коррупциягә каршы тәрбия бирүгә юнәлдерелгән материалларны бастыруны дәвам итәргә, шулай ук әлеге өлкәдә район структуралары эшчәнлеген даими яктыртырга.

10. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

11. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров